ГЛАВА ВАХИТОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.28, д. им. М. Вахитова,
422575

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ВАХИТОВ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Үзәк ур., 28 нче йорт, М. Вахитов исем авылы,
422575

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

л.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30

д. им. М. Вахитова

КАРАР

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Бакча-Сарай авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2023 елның 31 октябрендә «Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Бакча-Сарай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2024 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?- дигән сорау буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

- Бакча-Сарай бистәсендә спорт-уен мәйданчыгы төзү.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенының 170 катнашучысы, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 88 кеше кертелгән. Кворум бар.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлегенең  Бакча-Сарай авылында халык җыены булды, халык җыены нәтиҗәләрен  дөрес дип танырга.
2. "Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авылы җирлегенең  Бакча-Сарай авылында 2024 елда, авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән билгеләнгән ташламалы гражданнардан тыш, Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авылы җирлеге Бакча-Сарай авылында теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә  юллау белән килешәсезме? – Бакча-Сарай бистәсендә спорт-уен мәйданчыгы төзү,-  дигән сорау буенча карарны кабул итәргә.
3. Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Бакча-Сарай авылының халык җыены нәтиҗәләрен Вахитов авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына җибәрү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге башлыгына  җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче        Ф.Р. Каримов